**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**СОВЕТЫ**
**IV чакырылыш**
423740, Актаныш авылы, Ленин пр.,
17нче йорт. Тел. 3-44-44, факс 3-44-38.

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ АКТАНЫШСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**IV созыва**
423740, село Актаныш, пр. Ленина,
дом 17. Тел/. 3-44-44, факс 3-44-38.

**КАРАР**
14.02.2025 ел

**РЕШЕНИЕ**
№42-10

**«Актаныш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең муниципаль хезмәт вазыйфалары турында» 2025 елның 22 гыйнварендагы 41-04 номерлы Актаныш муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы» 2013 елның 23 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Актаныш муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. «Актаныш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең муниципаль хезмәт вазыйфалары турында» 2024 елның 06 августындагы 37-05 номерлы Актаныш муниципаль районы Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә һәм әлеге карарга кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә: «Актаныш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең муниципаль хезмәт вазыйфалары реестрыннан Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инвестицияләр һәм инновацион үсеш буенча урынбасары вазыйфасын чыгарырга, «Актаныш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге муниципаль хезмәте вазыйфалары реестрына Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының эшләр идарәчесе вазыйфасын кертергә.

2. Әлеге карарны «Актаныш таннары» район газетасында бастырып чыгарырга һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында (www.aktanysh.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Актаныш муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе И.Р. Вахитовка йөкләргә.

**Актаныш муниципаль районы**
**Советы рәисе** **Л.Р.Зарипов**